# Патриотик рухта тәрбиялик



Район үзәк китапханәсендә Бөек Җиңүнең 80 еллыгына багышланган «И помнит мир спасенный» әдәби-музыкаль чара узды. Анда мәктәп укучылары, өлкән буын вәкилләре һәм авыл китапханәчеләре катнашты. Бу чара яшь буынны патриотик рухта тәрбияләүгә багышланып, Ватанга карата мәхәббәт турында күп чыгышлар тыңланды. Илдә узган сугышларны хәтерләү һәм әлеге вакытта барган махсус хәрби операция яугирләренә карата горурлык хисләре турында аеруча сөйләнде. Шулай ук Кәшкәләү, Каенлык, Бадрак авыллары китапханәчеләре шушы төбәктән чыккан Советлар Союзы Геройлары турында да мәгълүмат бирделәр. Район ветераннар советы рәисе Фирдус Садретдинов сугыш чоры балаларының шул чордагы хезмәтләре турында сөйләде. Ә “Сугышчан туганлык” оешмасының Борай бүлекчәсе идарәсе рәисе Илгиз Вәлинуров үзенең хәрби юлы белән таныштырды. Бүгенге көндә махсус хәрби операциядә катнашучы Рамил Әхмәтовның әнисе Рәүфә апа йөрәк түреннән чыккан ялкыннары белән сугыш турында шигырен укып китте. Чара сугыш темасына багышланган җыр, бию белән үрелеп барды.

**Гөлназ ХУҖИНА.**